**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «23» августыннан № 345

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча административ регламентны раслау турында» 2019 елның 8 ноябрендәге 265 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча административ регламентны раслау турында» 2019 елның 8 ноябрендәге 265 номерлы карарының 3 бүлегендәге атамасында «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак эш урыннарында урнашкан үзәкләрдә» сүзләрен «үзәкләрдә» сүзләренә алмаштырырга. Бүлектә мөрәҗәгать итүчеләрнең уртак билгеләр белән берләшкән аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары булырга тиеш, алар мөрәҗәгать иткән дәүләт яки муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да».

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 27 декабрендәге 619 номерлы карарының 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 3.8.4 пунктын өстәргә:

«3.8.4. Административ регламент структурасы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан мәгълүмати технологияләр өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вәкил тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә, мондый хезмәт күрсәтү процедураларын автоматлаштыруны тәэмин итә торган тиешле хезмәт күрсәтү процедураларының машина белән укылган тасвирламасын күздә тотарга тиеш».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://parvo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www. novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов